**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның 17 апреленнән

№ 53-408

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Контроль-хисап палатасының 2024 елдагы эшчәнлеге һәм 2025 елга бурычлары турында хисабы

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 56 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмәнең 19 статьясы нигезендә Контроль-хисап палатасы рәисе Р. А.Губкинның Контроль-хисап палатасының 2024 елдагы эшчәнлеге һәм 2025 елга бурычлары турында хисабын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Контроль-хисап палатасының 2024 елдагы эшчәнлегенең хисабы һәм 2025 елга бурычлары турында хисабын игътибарга алырга.

2. Яңа Чишмә муниципаль районын Контроль-хисап палатасының 2024 елдагы эшен канәгатьләнерлек дип танырга.

3. 2025 елда Яңа Чишмә муниципаль районының Контроль-хисап палатасына:

3.1. Җирле үзидарә органнарын тотуга киткән чыгымнарны да кертеп, бюджет ассигнованиеләрен бюджетның барлык статьялары буенча тотуның законлылыгына һәм нәтиҗәлелегенә контрольлек итәргә;

3.2. Муниципаль берәмлек мике белән идарә итү һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен үтәүне контрольдә тотарга;

3.3. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә аудит үткәрергә;

3.4 Бюджет проектлары буенча экспертиза үткәрү һәм нәтиҗәләр бирү,район һәм авыл җирлекләре бюджеты үтәлеше буенча хисаплар бирү буенча эш алып барырга;

3.5. Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары хокукый актларына һәм аларның проектларына финанс-икътисадый экспертиза үткәрергә;

3.6. Вәкаләтләре чикләрендә коррупциягә каршы көрәшкә юнәлдерелгән чараларда катнашырга.

4. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына, авыл җирлекләре Башкарма комитетларына, муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

4.1. Бюджет акчаларын, муниципаль милекне макатчан кулланмауны булдырмаска, шул исәптән ягулык-майлау материалларын, аларны тулысынча нәтиҗәле куллануны тәэмин итәргә (хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү, билгеләнгән чыгым нормативларын үтәү);

4.2. Мөлкәткә һәм башка салымнар, кредиторлык (дебиторлык) бурычлары буенча вакыты чыккан недоимканы булдырмау чараларын үткәрергә;

4.3. Бухгалтерлык исәбе, финанс хисаплылыгы торышына һәм финанс-бюджет дисциплинасы дәрәҗәсенә аерым игътибар бирергә, аларның дәрәҗәсен күтәрү буенча чаралар күрергә;

4.4. Муниципаль сатып алулар өлкәсендә законнар таләпләрен үтәүне, шул исәптән сатып алуларның нәтиҗәлелеген контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;

4.5. Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән юридик затларга (муниципаль учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга финанс ярдәме күрсәтүнең билгеләнгән тәртибен сакларга;

4.6. Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә туклануны оештыруда билгеләнгән таләпләрне үтәргә;

4.7. Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль берәмлекләрендә эчке финанс контролен камилләштерү буенча эш алып барырга.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы — В. М. Козлов